ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

“23” ноябрь 2019 ел № 34

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы Катмыш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын
җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, гражданнар җыеннары карарларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлеге:

2019 елның 23 ноябрендәге 1 санлы «Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге составына керә торган Еники Чишмә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башкарма комитеты;
2019 елның 23 ноябрендәге 2 санлы «Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге составына керүче Катмыш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башкарма комитеты;
2019 елның 23 ноябрендәге 3 санлы «Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге составына керүче Баскан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан

Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге Советы рәисе /И.Г.Габидуллин/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының 23 ноябрь
2019 ел, 34 нче санлы карарына 1
нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2020 елның 26 мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, түли.

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының 23 ноябрь 2019 ел,
34 нче санлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш Муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге
*(муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № ______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_______________________________________________________________

Адрес: ________________________________________________________

Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең __________ авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2020 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 2020 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр 500 сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: УФК по РТ (Финансово-бюджетная палата Мамадышского муниципального района РТ)

Кабул итүче як банкы БИК ___________________________________
Сч. № ______________________________
Кабул итеп алучы Сч. № _____________________________________
ИНН _______________________________________
КПП _______________________________________
КБК ______________ ОКАТО _________________
Түләүнең билгеләнеше
Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче _______________ ______________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -**

_______________________________________________________
*(муниципаль берәмлек исеме)*

______________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № ______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_______________________________________________________

Адрес:
_______________________________________________________________

«__» ______________ 20__ г. ____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)______________ авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*